**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail:
aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail:
aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» ноябрь 2020 ел** **№ 297**

Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай районы Тымытык сугару системасын үзгәртеп кору» линияле объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы чикләрендә урнашкан « Татарстан Республикасы Азнакай районы Тымытык сугару системасын реконструкцияләү» линияле объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы.

3. Билгеләргә:

үткәрү вакыты: 2020 елның 27 ноябреннән 2020 елның 28 декабренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны: Азнакай ш., Ленин ур., 22;

- 2020 елның 28 декабренә кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Азнакай шәһәре, М.Солтангалиев урамы, 24 нче йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге (эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр).

4. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына:

- 1. Азнакай муниципаль районы чикләрендә урнашкан « Татарстан Республикасы Азнакай районы Тымытык сугару системасын реконструкцияләү» линияле объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмтының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М. З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
башлыгы карарына кушымта
« ___» _______ 2020 №_____

Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай районы Тымытык сугару системасын үзгәртеп кору» линияле объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А. Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р. Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Шәрәфетдинова С. Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Закирова З. З. | Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе) |
| Гыйләҗева Э. Х. | Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе) |